РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ АКСУНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКСУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

12 май 2021 ел

№ 21-1

ТР Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. ТР Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 февралендәге 2-30 номерлы «Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында»гы карары (28.06.2016 № 14-2, от 23.09.2017 № 36-1, от 11.02.2019 № 65-1 карарлары редакциясендә) (алга таба - Кагыйдәләр) белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 11 статьясы:

3 пунктка 6 пунктны түбәндәге редакциядә өстәргә:

«6) территорияне комплексלы үстерү турында карар кабул итү.»;

4 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Кагыйдәләргә үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр комиссиягә җибәрелә:

федераль башкарма хакимият органнарыннан, әгәр кагыйдәләр федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, әгәр кагыйдәләр региональ әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда;

Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан, кагыйдәләр муниципаль районның җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда;

Аксу авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан, әгәр авыл җирлегенең тиешле территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруны җайга салу тәртибен камилләштерергә кирәк булса;

физик яки юридик затлар тарафыннан инициатив тәртиптә, яисә киләсе очракларда, әгәр җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары Кагыйдәләрен куллану нәтиҗәсендә нәтиҗәле файдаланылмаса, аларның хокук ияләренә зыян килсә, капиталь төзелеш объектларының һәм җир кишәрлекләренең бәясе кимесә,

гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре тормышка ашырылмаса;

территорияне комплекслы үстерү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче федераль башкарма хакимият органы яисә юридик зат тарафыннан (алга таба - Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнгән юридик зат);

Татарстан Республикасы төзегән һәм Татарстан Республикасы тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турында карарны (алга таба - Татарстан Республикасы билгеләгән юридик зат) яисә территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Буа муниципаль районының җирле үзидарә органы тарафыннан.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркеме төзергә:

-эшче төркем җитәкчесе:

Хәйретдинов Марат Мөнир улы– Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы,

-эшче төркем әгъзалары:

Шәрәфуллина Гөлназ Илдус кызы – Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре (килешү буенча);

Сибгәтуллин Әнсар Мансур улы – Буа муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе (килешү буенча);

Валеева Резедә Нәгыйм кызы – Буа муниципаль районы Советы Аппаратының авыл җирлекләре белән эшләү бүлеге башлыгы (килешү буенча),

Усманова Айгөл Марат кызы – Буа муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге баш белгече (килешү буенча).

4.Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422415, ТР, Аксу авылы, Үзәк ур., 116а нчы йорт, язма рәвештә, карар проекты рәсми басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларда катнашып, чыгыш ясау хокукы өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422415, ТР, Аксу авылы, Үзәк ур., 116а нчы йорт, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулары үткәрү турында нигезләмәдә каралган тәртиптә әлеге проект буенча ачык тыңлауларны 2021 елда “10” июньгә 9.00 сәгатьтә Аксу авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында ТР, Буа районы, Аксу авылы, Үзәк ур., 116а нчы йорт адресы буенча үткәрергә.

5. Эшче төркемгә ТР Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектына тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Аксу авыл җирлеге башлыгы М.М. Хәйретдинов